**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ИЛТЕРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№14 16.12.2020 ел

**Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 ел, 5 ноябрь, 111 нче карарына үзгәрешләр кертү турында (2019 ел, 15 ноябрь, 112 нче карарына үзгәрешләр кертү белән)**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 20 июль, 236-ФЗ номерлы Федераль закон , Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Уставы нигезендә Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советы тарафыннан «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 ел, 5 ноябрь, 111 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1.1. Нигезләмәнең 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 абзац өстәргә:
- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә,, инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча»;
2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә
3. Иске Илтерәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән карарны халыкка игълан итәргә: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе С.М. Маклаков